| | | |
|---|---|---|
| **РАСПОРЯЖЕНИЕ**<br>РАИСА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>РӘИСЕ<br>**БОЕРЫГЫ** |
| 11.05.2023 | | № 164 |

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына ирешү буенча чаралар координаторлары һәм Татарстан Республикасында Россия Федерациясе субъектлары югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимияте югары башкарма органнары җитәкчеләренең) эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрнең үтәлеше өчен җаваплы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары исемлеген раслау турында» боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына ирешү буенча чаралар координаторлары һәм Татарстан Республикасында Россия Федерациясе субъектлары югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимияте югары башкарма органнары җитәкчеләренең) эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрнең үтәлеше өчен җаваплы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары исемлеген раслау турында» 2021 елның 19 мартындагы 116 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Президентының 2021 елның 2 июнендәге 176 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәреше белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына ирешү буенча чаралар координаторлары һәм Татарстан Республикасында Россия Федерациясе субъектлары югары вазыйфаи затлары эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләренең үтәлеше өчен җаваплы республика башкарма хакимияте органнары исемлеген раслау турында»;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы һәм «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма органнары эшчәнлегенең

нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы указларын гамәлгә ашыру максатларында:»;

1 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимияте органнары» сүзләренә алмаштырырга, «(дәүләт хакимияте югары башкарма органнары җитәкчеләренең)» сүзләрен төшереп калдырырга, «башкарма хакимият органнары» сүзләрен «башкарма органнар» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына» сүзләрен «Республика башкарма хакимияте органнарына» сүзләренә алмаштырырга, «(дәүләт хакимияте югары башкарма органнары җитәкчеләренең)» сүзләрен төшереп калдырырга, «башкарма хакимият органнары» сүзләрен «башкарма органнар» сүзләренә алмаштырырга;

«д» пунктчасында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләренә халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсе» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген һәм халыкның тормыш сыйфатын бәяләү индикаторлары» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимияте органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

Татарстан Республикасында Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына ирешү буенча чаралар координаторлары һәм Татарстан Республикасында Россия Федерациясе субъектлары югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимияте югары башкарма органнары җитәкчеләренең) эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрнең үтәлеше өчен җаваплы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары исемлегендә:

атамасында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына» сүзләрен «Республика башкарма хакимияте органнарына» сүзләренә алмаштырырга, «(дәүләт хакимияте югары башкарма органнары җитәкчеләренең)» сүзләрен төшереп калдырырга, «башкарма хакимият органнары» сүзләрен «башкарма органнар» сүзләренә алмаштырырга;

таблица исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| Т/с | Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары һәм Россия Федерациясе субъект-ларының башкарма | Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары эшчән-легенең һәм Россия Федерациясе субъектлары-ның башкарма органнары | Татарстан Республика-сында Россия Федерациясе үсешенең илкүләм |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| | органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечнең атамасы | эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечен үтәү өчен җаваплы республика башкарма хакимият органнары | максатларына ирешү чаралары координаторы |

»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | Хакимияткә ышаныч (Россия Федерациясе Президентына, Россия Федерациясе субъект-ларының югары вазыйфаи затларына ышаныч, аның дәрәҗәсе Россия Федерациясе субъект-ларында Россия Федерациясе үсеше-нең илкүләм максат-ларына ирешүгә карата җәмәгатьчелек фикерен бәяләү юлы белән билгеләнә) | Республика башкарма хакимияте органнары | Сәфәров Әсгать Әхмәт улы – Татарстан Республикасы Рәисе Администра-циясе Җитәкчесе* |

»;

16 пунктның «Татарстан Республикасында Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына ирешү чаралары координаторы» графасында «Кәримов Альберт Әнвәр улы» сүзләрен «Коробченко Олег Владимирович» сүзләренә алмаштырырга;

17 пунктның «Татарстан Республикасында Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына ирешү чаралары координаторы» графасында «Кәримов Альберт Әнвәр улы» сүзләрен «Коробченко Олег Владимирович» сүзләренә алмаштырырга;

18 пунктның «Татарстан Республикасында Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына ирешү чаралары координаторы» графасында «Кәримов Альберт Әнвәр улы» сүзләрен «Коробченко Олег Владимирович» сүзләренә алмаштырырга;

искәрмәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«* Татарстан Республикасында Россия Федерациясенең югары вазыйфаи субъектлары эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечен үтәү чаралары координаторы.».

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**